Ситдыйкова, Ә. Сыйдыралмый аңы : Шагыйрь Айрат Суфияновка: шигырь / Ә. Ситдыйкова. – Текст: турыдан-туры, электрон // Мәдәни җомга. – 2024. – №48 (6 декабрь). – Б. 7. – URL: https://madanizhomga.ru/news/kykregemde-shigyir-utyim-saumyi/alfiia-sitdyikova-gam-galamen-kicep-atlyi-sagyir-kulga-totyp-kainar-ioragen. – Чыгу вакыты: 07.12.2024

## СЫЙДЫРАЛМЫЙ АҢЫ



*Шагыйрь Айрат Суфияновка*

«Сызлап, актарылып, үксез йөрәк булып»
Яшәр өчен түгел, яшьнәр өчен килгән
Шагыйрь сорау ала: «Бөтен дөнья нигә
Каршылыклы?!» – диеп саташулы илдән.

Телгәләнгән йөрәк җавап таба алмый,
Читлектәге коштай бәргәләнә җаны.
Кайда караса да: күрә кабер ташын,
Сыйдыралмый шуны аның бөек аңы.

«Әллә яшим җирдә, әллә сүнеп барам... » –
Беләм, шагыйрь, тирән синең йөрәк яраң.
Илнең фаҗигасен карашыңа салып,
Язасың син шигырь, кипмәсен лә караң.

Каурый каләмеңдә караң беткән чакта,
Язарсың син җырың, йөрәк каның белән.
Әрнеп каһәрләргә тумагансың җиргә,
Яшен кебек яшьнәп яшәр өчен килгән.

Тулырак: https://madanizhomga.ru/news/kykregemde-shigyir-utyim-saumyi/alfiia-sitdyikova-gam-galamen-kicep-atlyi-sagyir-kulga-totyp-kainar-ioragen